**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Яңа Сумароково авыл җирлегенә керүче Яңа Сумароково авылында гражданнар җыены карары**

**Яңа Сумароково авылы 2021 елның 11 декабре.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Яңа Сумароково авыл җирлегенең Яңа Сумароково авылында гражданнар җыены

**Карар итте:**

1. 2022 елда гражданнарның үзара салымын Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Яңа Сумароково авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылардан, тыл хезмәтчәннәреннән тыш, 300 сум күләмендә билгеләргә.
2. Җыелган акчаларны Яңа Сумароково авылында балалар мәйданчыгы өчен спорт-уен җиһазлары сатып алуга юнәлдерергә.

**Халык җыенында рәислек итүче-**
**Яңа Сумароково авыл җирлеге башлыгы Р. М. Паневкина**